ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21. 10. 2025 г.Мензелинск № 345

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 24.07.2018 ел № 782 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.05.2018 ел № 412 «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.10.2018 № 965, 29.12.2018 № 1262, 06.05.2019 № 380, 28.08.2019 № 714, 02.11.2019 № 1008, 30.12.2019 № 1278, 16.04.2020 № 294, 21.05.2020 № 413, 01.09.2020 № 772, 23.10.2020 № 954, 26.07.2021 № 645, 06.09.2021 № 821, 29.10.2021 № 1021, 30.10.2021 № 1030, 15.06.2022 № 566, 22.09.2022 № 1027, 11.03.2023 № 232, 19.08.2023 № 989, 16.10.2023 № 1312, 31.10.2023 № 1377, 07.11.2023 № 1431, 11.05.2024 № 318, 24.06.2024 № 454, 25.09.2024 № 830, 30.12.2024 № 1273, 21.04.2025 № 252, 19.06.2025 № 444 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 24.07.2018 елгы №782 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

3.2 пунктының икенче абзацында "тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре" сүзләре белән алыштырырга;

3.3 пунктында:

3.3.1 пунктының беренче абзацында "тормыш иминлеге нигезләре һәм хәрби хезмәткә әзерлек укытучылары-оештыручылары" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре укытучылары-оештыручылары" сүзләре белән алыштырырга;

3.3.2 пунктының беренче абзацында "тормыш иминлеге нигезләре һәм хәрби хезмәткә әзерлек укытучылары-оештыручылары" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре укытучылары-оештыручылары" сүзләре белән алыштырырга;

3 нче таблицаның "Мәгариф оешмалары, шул исәптән югары белем бирүче мәгариф оешмалары, югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри мәгариф оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү); медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йорты, балалар: санаторийлар, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б." юлындагы 2 нче графасында "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек)" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре" сүзләре белән алыштырырга;

5.2 пунктының 5.2.6 пунктының икенче абзацында "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек)" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре" сүзләре белән алыштырырга;

5.7 пунктының 5.7.9 пунктының 9 нчы таблицаның 3.19 пунктының 2 нче графасында "тормыш иминлеге" сүзен" һәм Ватанны саклау" сүзләре белән алыштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

таблицаның 3 нче графасының 2 нче юлында "Мәгариф оешмалары, шул исәптән югары белем бирүче мәгариф оешмалары, югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри мәгариф оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү); медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йорты, балалар: санаторийлар, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б." сүзләрен "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек)" сүзләре белән алыштырырга;

5.2 пунктының 5.2.6 подпунктындагы икенче абзацта "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек)" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре" сүзләре белән алыштырырга.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

таблицаның 2 нче графасының "Мәгариф оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирү хәрби оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү); медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йорты, балалар өчен: санаторийлар, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б." юлларын 3 сүзен "тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре сүзләре белән алыштырырга;

5.2 пунктының 5.2.6 подпунктындагы икенче абзацта "тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә әзерлек" сүзләрен "иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре" сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Финанс-бюджет палатасы" МКУ рәисе Кондратьева Ландыш Илдусовнага һәм Минзәлә муниципаль районының "Мәгариф бүлеге" МКУ җитәкчесе Ибраһимов Ренат Мәхмүт улына йөкләргә.

Җитәкче М.Р.Кәримов